Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
Ислəй авыл җирлеге Советы

КАРАР

2024 елның 12 сентябре № 45/1

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Ислəй авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Ислəй авыл җирлеге» муниципаль берəмлеге муниципаль милкендəге кече һəм урта эшкуарлык субъектлары арендалый торган күчемсез мөлкəтне тартып алу турындагы нигезлəмəне раслау хакында» 2019 елның 24 сентябрендəге 66/2 номерлы карарына үзгəрешлəр кертү турында

«Дəүлəт мөлкəтен һəм муниципаль мөлкəтне хосусыйлаштыру турында «Федераль законга һəм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгəрешлəр кертү хакында» 2024 елның 6 апрелендəге 76-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендə Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының Ислəй авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Ислəй авыл җирлеге Советының 2019 елның 24 сентябрендəге 66/2 номерлы карары белəн расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Ислəй авыл җирлеге» муниципаль берəмлеге муниципаль милкендəге кече һəм урта эшкуарлык субъектлары тарафыннан арендага алына торган күчемсез мөлкəтне читлəштерү турындагы нигезлəмəгə түбəндəге үзгəрешлəрне кертергə:
3.1 пунктның 1 пунктчасында «ике ел» сүзлəрен «бер ел» сүзлəренə алмаштырырга.

2. Əлеге карарны билгелəнгəн тəртиптə халыкка җиткерергə һəм Чистай муниципаль районының рəсми сайтына (www.chistopol.tatarstan.ru) урнаштырырга.

Ислəй авыл җирлеге
Башлыгы В.П. Чернышев